КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 15

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 февраль, 132 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен раслау турында» 2022 ел, 16 февраль, 132 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 4 июнь, 403 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8 пунктта «календарь» сүзен «эш» сүзенә алмаштырырга;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Координацияләү органы әлеге Тәртипнең 2.9 пунктында каралган, концессия килешүе проектын килештерүдән баш тартуны үз эченә алган җавап кергән көннән алып биш календарь көннән дә соңга калмыйча җирле үзидарә органына, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.10^1$ – $2.10^3$ пунктлар өстәргә:

«$2.10^1$. Тәкъдим һәм аңа теркәлә торган концессия килешүе проекты әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килгәндә, координацияләү органы әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән тәкъдим күчермәсе кергән көннән алып яки әлеге Тәртипнең 2.9 пунктында каралган, концессия килешүе проектын килештерүне үз эченә алган җавап кергән көннән алып җиде эш көне эчендә тәкъдим күчермәсен һәм аңа теркәлә торган концессия килешүе проектын Татарстан Республикасы Премьер-министрына килештерүгә җибәрә.

$2.10^2$. Координацияләү органы тәкъдим күчермәсен һәм аңа теркәлә торган концессия килешүе проектын килештерүдән баш тарту кергән көннән алып өч эш көне эчендә җирле үзидарә органына, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, концессия килешүе проектын килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

Координацияләү органы Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан тәкъдим күчермәсе һәм аңа теркәлә торган концессия килешүе проекты килештерелгән көннән алып өч эш көне эчендә аларны Татарстан Республикасы Рәисенә килештерүгә җибәрә.

$2.10^3$. Координацияләү органы, әлеге Тәртипнең $2.10^2$ пунктында каралган килештерү яки килештерүдән баш тарту алынган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, җирле үзидарә органына концессия килешүе проектын килештерү яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килештерүдән баш тарту турында бәяләмә җибәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.10^1$ – $3.10^3$ пунктлар өстәргә:

«$3.10^{1}$. Координацияләү органы әлеге Тәртипнең 3.10 пунктында каралган, концессия килешүе проектын килештерүдән баш тартуны үз эченә алган җавап кергән көннән алып биш календарь көннән дә соңга калмыйча җирле үзидарә органына, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

$3.10^{2}$. Концессия килешүе проекты әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килгәндә, координацияләү органы әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән иярткүле хат һәм документлар алынган көннән алып яки әлеге Тәртипнең 3.10 пунктында каралган, концессия килешүе проектын килештерүне үз эченә алган җавап кергән көннән алып җиде эш көне эчендә концессия килешүе проектын Татарстан Республикасы Премьер-министрына килештерүгә җибәрә.

$3.10^{3}$. Координацияләү органы Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан концессия килешүе проектын килештерүдән баш тартылган көннән алып өч эш көне эчендә конкурс оештыручыга, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, концессия килешүе проектын килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

Координацияләү органы Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан килештерелгән концессия килешүе проекты кергән көннән алып өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Рәисенә килештерүгә җибәрә.»;

3.11 һәм 3.12 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Координацияләү органы әлеге Тәртипнең $3.10^{3}$ пунктында каралган килештерү яки килештерүдән баш тарту кергән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс оештыручыга концессия килешүе проектын килештерү яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килештерүдән баш тарту турында бәяләмә җибәрә.

3.12. Алынган килештерү яки килештерүдән баш тарту турында координацияләү органы бәяләмәсен, әлеге Тәртипнең 3.5, $3.10^{3}$, 3.11 пунктларында күрсәтелгән җавапны, килештерүне яки килештерүдән баш тартуны исәпкә алып, концессия килешүе проектын килештерү мөмкин булмаганда, концессия килешүе проектын килештерүдә катнашкан һәм концессия килешүе проектын карау йомгаклары буенча аны төзү мөмкин булмау турында нигезле нәтиҗәләр белән җаваплар биргән республика башкарма хакимият органнары җирле үзидарә органының инициативасы белән аның белән концессия килешүе проекты нигезләмәләрен эшләп бетерү буенча сөйләшүләрдә катнаша.»;

4.9 пунктта «дүрт» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эл.Хөк., А.М.Сәгыйтова